ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СЕЛО-АЛАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422721, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Село-Алат, ул. Первомайская, 32

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422721, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алат авылы, Первомай ур., 32

тел./факс 8(84365) 63-2-25, e-mail: Salat.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

24апрель 2015 ел № 6

**Алат авыл җирлегендә 2015 елның апрель – июль айларында хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга хәбәр итү һәм илтеп җиткерү турында**

«Оборона турында» 31.05.1996 ел, № 61-ФЗ, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 28.03.1998 ел, №53-ФЗ, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру турында нигезләмәне раслау турында» гы 2006 елның 11 ноябрендәге 663 номерлы карары нигезендә, запаста булмаган һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле 18-27 яшьләрдәге Алат авыл җирлеге гражданнарын хәрби хезмәткә вакытында һәм сыйфатлы итеп әзерләү максатыннан, 2015 елның апрель - июль айларында»,

КАРАР БИРӘМ:

1. Хәрби хезмәткә чакырылучыларга хәрби хезмәткә чакырылуга бәйле чаралар үткәрү өчен хәбәр итүне оештырырга.
2. Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның үз вакытында оештырылуын тәэмин итәргә.
3. Участок уполномоченные А.А. Вәлиевка хәрби хезмәткә чакырылудан качып йөрүче егетләрне Биектау районы Хәрби комиссариаты бүлегенә килүен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәм.
4. Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле барлык милек формасындагы предприятие һәм оешма җитәкчеләренә хәрби хезмәткә чакыру компаниясе үткәрү чорында торак пунктлардан читкә чыгу белән бәйле эш һәм хезмәт вазыйфаларын үтәүдән азат ителәләр.
5. Әлеге карарны Алат авыл җирлегенең мәгълүмат стендында һәм Биектау муниципаль районының интернет челтәрендә урнаштырырга.
6. Әлеге карар Алат авыл җирлегенең мәгълүмат стендында һәм Биектау муниципаль районының интернет челтәрендә рәсми рәвештә халыкка җиткерелергә тиеш.

Алат авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ш.Шакиров